КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 19 июль г.Казань № 602

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2018 ел, 27 сентябрь, 860 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2018 ел, 27 сентябрь, 860 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 12 октябрь, 919 нчы; 2019 ел, 11 март, 169 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган аерым дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарны һәм аларның күләмнәрен.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарда:

4 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4.4 нче пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «4.4. | «Татарстан Республикасының Киңлек мәгълүматлары фонды» | мәгълүмат ресурсларын һәм мәгълүмат | 10 537 500,0»; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | дәүләт бюджет учреждениесе» | базаларын алып бару | |

11.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «11.1. | «Хайваннар дөньясын саклап калу өлкәсендә инновацион технологияләрне кулланышка кертү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | табигать комплексла-рын, уникаль һәм эталон табигать участокларын һәм объектларын саклап калу | 11 367 320,0 |
| | | хайваннар дөньясы (шул исәптән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган) объектларын һәм аларның мохитен саклап калу буенча чара-лар үткәрүне тәэмин итү | 2 820 180,0 |
| | | елгалар участокларын, сусаклагычларны һәм башка су объектларын чистарту, чишмәләр территориясен төзеклән-дерү | 197 100,0»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарның һәм аларның күләмнәренең 1.1 нче пункттагы 4 графада «189 290,0» саннарын «215 157,92» саннарына алыштырырга;

әлеге карарга Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган аерым дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарны һәм аларның күләмнәрен (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы                                        Р.К.Нигъмәтуллин